Татарстан Республикасы  Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле   авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

30  декабрь 2019 ел №  129

2016 елның 20 апрелендәге 23 номерлы «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында" гы карарына үзгәрешләр кертү турында»

«Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында” гы Федераль законга һәм 2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Иске Казиле авыл җирлеге Советының 2016 елның 20 апрелендәге 23 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертергә, һәм 15 статьяның 2 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"6) хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелу очракларыннан тыш, индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, шул исәптән электрон документ формасында.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән  алынганнан соң түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә:
1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;
2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Каратал авылы, Күпер урамы, 5;
3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк урамы, 14;  һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Иске Казиле
авыл җирлеге башлыгы, Татарстан
Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге
Советы рәисе И.Х.Сагьдиев